| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018 елның 13 декабре №81

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2012 елның 10 апрелендәге 14нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (2018 елның 17 маендагы 33нче номерлы редакциядә)

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турындагы” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Россия Федерациясенең Гражданнар кодексы, Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы” Уставы, Лениногорск муниципаль районы Советы регламенты нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1 Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының 2012 елның 10 апрелендәге 14нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 15.1 пункттагы «, оештыру формаларына бәйсез рәвештә оешма җитәкчеләре белән» сүзләрен гамәлдән чыгарырга; б) 16.1пунктында «, оештыру формаларына бәйсез рәвештә оешмалар» сүзләрен гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск муниципаль районы башлыгы урынбасары С.В.Тимаковка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы,

Совет рәисе Р.Г. Хөсәенов